ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕКОНДРАТИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422959, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
д. Верхняя Кондрата, ул. Центральная, 35/1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ КОНДРАТА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422959, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Югары Кондрата авылы,
Үзәк урамы , 35/1

тел.(факс)8(843)42 3-04-35, e-mail: Vkondr.Ctp@tatar.ru

Постановление Карар

22 март 2023 ел № 15

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Югары Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмөшле лампалар туплану урынын билдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында

1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»гы 89-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында»гы 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Энергияне саклау һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль законнарга ярашлы рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2020 елның 28 декабрендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән яктырту җайланмалары, электр лампалары, тиешенчә җыемнар, туплау, куллану, зарарсызландыру һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган калдыклар белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында»гы 2314 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигездә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Югары Кондрата авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Югары Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә (алга таба - муниципаль берәмлек) терекөмешле лампалар туплау урынын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Югары Кондрата авылы, Чалмаев авылы, 4 йорт адресы буенча урнашкан Югары Кондрата авыл җирлеге администрациясе бинасында (бинаның 1 катындагы ярдәмче бүлмә).

2. Күпфатирлы йортларның милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары өчен яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү Кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган 4 пункт нигезендә билгеләнә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән терекөмешле лампаларның туплану урыннары, шул исәптән терекөмешле лампаларны кулланучылар өчен дә билгеләнгән, алар күпфатирлы йортларда милекчеләр, яллаучылар, биналардан файдаланучылар булып торалар, әгәр бу күпфатирлы йортларда терекөмешле лампаларның туплану урыннарын оештыру мөмкин булмаса.

4. Кулланучыларга муниципаль берәмлек территориясендә терекөмөшле лампалар тупланган урынның урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга, муниципаль берәмлекнең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Югары Кондрата авылы
җирлеге Башлыгы Ф.П. Чалмаев